

Атюрьево районында Россия Федераль Жыены Дәvләт Думасы депутаты, «Бердәм Россия» фракциясе житәкчесенен беренче урынбасары, муниципаль берәмлекләрнен Гомумроссия конгрессы президенты Виктор Борисович Кидяев булып китте. Халык белән очрашканда, Стрельниково авыл жирлеге башлыгы Саид Загидулла улы Кильдеев, депутатка топ соравын – Стрельников авылындагы Кулунчаков морза йортынын киләчәк язмышы турында кайгыртып морәжәгать итте.

Әлегә республикада татарлар токымы вәкиленен бердән-бер сакланып калган помещик утары урыны бу: ат абзары бинасы, хезмәтчеләр йорты, 1814 елда Напалеонны жинv истәлегенә утырткан юкә аллеясы һәм башкалар. Усадьба архитектура һәйкәле буларак теркәлгән. Саид Загидулла улы утарны торгызуда һәм туристлык Үзәген булдыруда ярдәм итv vтенече белән морәжәгать иткән.
Кыскача Кулунчаковлар турында. Кулунчаковлар (морза Кулунчаковлар, Колынчаклар) – татар, сонрак рус морзалар токымы. Темник морзасы Кулунчак Еникеевтан килеп чыга. Еникей Тенишев морзанын олкән улы ул һәм әтисе vлгәч Темниковта житәкчелек тә иткән ул.
Утарны Алексей Николаевич Кулунчаков тозегән. Ул 1815 елда гардемарин (1818 елда дингез кадет корпусын тәмамлаган), 1834 елга кадәр флотта капитан-лейтенант булып хезмәт иткән. Балтик, Алман, Тоньяк, Урта Дингез Һәм Кара дингезләрдә алты ай йоргән. 1828-1829 елларда - рус-торек сугышында, 1830-1831 елларда Польша восстаниесен бастыруда катнашкан. Кvпторле олы бvләкләре бар. 1839 елда майор дәрәжәсенә ирешкән. Казан губернасы урманчысы булып хезмәт иткән, 1843 елнын 25 маенда подполковник мундиры белән отставкага киткән.
Кулунчаковлар 1452 елда Василий II тарафыннан нигез салынган Касыйм патшалыгы тормышында сизелерлек сәяси (политик) роль уйнаганнар. Александр Иванович Купріннын әнисе - Любовь Алексеевна Кулунчакованын ерак туганы XIV гасырда Сараклыч шәһәре житәкчесе (хәзерге заман Саров, элекке Арзамас-16) Бехан морза булган. Тенишевлар, Кугушевлар, Еникеевлар, Акчуриннар, Ишеевлар һәм Кулунчаковлар – барысы да Беханнын дәвамы булган токымнар. Вакытлар узу белән, әлеге морза фамилияләр вәкилләре, жирләрен һәм титулларын югатмас очен, дәvләткә хезмәт итә башлыйлар һәм православиене дә кабул итvчеләре була.

Николай Алексеевич Кулунчаков утарын (урман сагы һәм Хәрби ведомство вәкиле, князь, Казан губернасы урманчысы, статский советник) тозегән. Бу нәселнен 2160 га мәйданда жиләк-жимеш бакчасы, 1912 елда Наполеонны Жинvнен 100 еллыгы унаеннан утыртылган аллея, сәvдә йортлары белән 79 мен чиләк спирт житештерvче заводы була. Ашлык, бәрәнге vстерv, терлекчелек һәм умарта vрчетv белән шогыльләнvче крестьяннарга кредитлар биргән банкы да эшләгән. Ат абзарында армия очен атлар vрчеткән. 1914 елда, Беренче ботендонья сугышы башланганда, биналарынын берсендә яралыларга госпиталь ачкан. Болар барысы да рус язучысы Александр Иванович Куприннын ата-бабаларынын, Колынчаков морзанын булган. 1905 елда агач йорт яна һәм Николай Алексеевичнын улы Алексей, немец стилендә ике подъезды, ике балконы һәм пыяла террасасы булган таш бина този. Шул бина рәсемдә.
Тарихыбызны белергә тиешбез һәм аны саклау максаты белән утарны торгызу, туристлар танышсын очен яна момкинчелек тудыру турында очрашуда сvз барган.

**Н.Хәлил**